
# “Татар телендә теркәгечләр һәм хәзерге шигъриятtә аларның кулланылышы”

- *Җөмлә кисәкләрен һәм кушма җөмлә өлешләрен үзара бәйләү өчен кулланыла торган сүз төркеме* ***теркәгеч*** *дип атала.Башка ярдәмлекләр шикелле үк, теркәгечләр дә реаль мәгънәгә ия түгел.*

# Каюм Насыйри карашлары

- 1) Каршы куючы теркәгечләр: ләкин,әмма,гәрчә.
- 2)Охшату-чагыштыру теркәгечләре: кебек,кеби,сыман,шикелле,төсле.
- 3)Аңлату теркәгечләре: бәйан,ки,хәтта.
- 4)Бүлүче теркәгечләр: яки,җә.
- 5)шарт теркәгечләр: әгәр,әгәр дә ,бәнәгаһ.



# В.Н.Хангильдин карашлары

- ***1.Тезүче теркәгечләр***
- *А)җыючы теркәгечләр*: һәм,тагын,янә,ни;
- *Ә)каршылык теркәгечләре:* ләкин,тик,бары,ә,бәлки,әмма,мәгәр;
- *Б)бүлгәләүче теркәгечләр:* я(йә),яки,яисә.

- ***2.Ияртүче теркәгечләр.***
- *А)сәбәп теркэгәче* – чөнки;
- *Ә)охшату-чагыштыру теркәгече-* гүя(ки);
- *Б)шарт теркәгече* – әгәр(гәр);
- *В)киеренкелек теркәгече* – гәрчә;
- *Г)аныклау теркәгече* – ки.

# *Хәзерге шигърияттә тезүче теркәгечләрнең кулланылышы*

Җыючы теркәгечләр



- Җимерек өйдә яши кыз бала,

  Куркыныч һәм авыр аңа...

  Һәм шул ядкәр киләчәккә

  Тәрәз шакый ( Р.Вәлиева)

- Көлдергән дә, елаткан да-

  Бөтенесен булдырган (Ф.Яруллин)

# Каршы куючы теркәгечләр

- Ләкин инде күпме үкенсәң дә


  Бер киткәннәр кайтмый яңадан (Ф.Яруллин)

- Сүз җибәрдем ... Яхшыларга,

  Бәлки, әле яхшы булыр ( М.Әгъләмов)

- ...Әмма дуслык исән,

  Дәвам итә дуслык һаман да!...(Р.Миңнуллин)



## Бүлүче теркәгечләр

- ...Яки сикереп төшәр идек
  Сагышлар елгасына (Ф.Яруллин)

- Тавышларын кайчак танымыйча торсам
  Яки бер көн үзем шундый хәлдә булсам,
  Мине кинәт акыл шул кичәгә сөйри (М.Әгъләмов)

# Хәзерге шигърияттә ияртүче теркәгечләрнең кулланылышы

- Хәтта дуслар: “Син ничауа егет!”-
  Диеп мактадылар килгәндә.
  Син аларны яратырсың.Әнкәй,
  Чөнки алар әйбәт миннән дә! (Р.Миңнуллин)

- Гомеремдә бер очратсам әгәр
  Синдәй яратканның баласын,
  Әйтер идем...(Р.Вәлиева)